**Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл җирлеге Советы өченче чакырылыш утырышы**

**Карары**

**25 июль 2019 ел** **№ 128** **Шәтке авылы**

**Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлау буенча сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен Теләче муниципаль районы Шәтке авыл җирлеге территориясендә махсус урыннар билгеләү турында**

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең «Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауда сайлау алды агитация материалларын урнаштыру һәм җиһазлау өчен һәр сайлау участогы территориясендә махсус урыннар бүлеп бирү турында Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгать итү турында»гы 2019 елның 10 июлендәге 67/516 номерлы карарын карап, Татарстан Республикасы Сайлау Кодексының 64 статьясындагы 8 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл җирлеге башкарма комитеты,

**КАРАР БИРӘ:**

1. Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлау буенча сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен Теләче муниципаль районы Шәтке авыл җирлеге территориясендә түбәндәге махсус урыннарны билгеләргә:

- Шәтке авылы , Габдуллы Галиев урамы, 6 йорт, шәхси эшмәкәр “Хакимова” кибете бинасында мәгълүмат стенды;
- Шәтке авылы , Мәктәп урамы, 4 йорт, Шәтке урта мәктәбе бинасында мәгълүмат стенды;
- Шәтке авыл, Ленин урамы, 21 йорт, Шәтке ветеринария пункты бинасында мәгълүмат стенды;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Теләче районы территориаль сайлау округына җибәрергә.
3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.
4. Әлеге карарны Шәтке авылы,Г.Тукай урамы, 7 йорт, Шәтке авыл җирлеге хакимияте бинасы адресы буенча Шәтке авыл җирлеге мәгълүмат стендында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Теләче муципаль районы
Шәтке авыл җирлеге башлыгы Ф.Г.Кадыйров